| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ӘХМӘТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әхмәт ав. **КАРАР**

29 март 2024 ел № 4

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 11 апрелендә сәгать 15 сәгать 00 минутка Кооператив урамы, 78 адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Кооператив урамы 1-61нче йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2024 елның 11 апрелендә сәгать 16 сәгать 00 минутка Кооператив урамы, 78 адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Кооператив урамы 2-76нчы йортларда, Шоссе урамында яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны распарга:

«Сез элек расланганнарга үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 16 ноябрендәге 7 номерлы карары

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогында гражданнар Җыенының 16.11.2023 ел, № 8 карары,

түбәндәге редакциядә раслап:

«Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Шишмә поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, 85 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче граждааннар, СВОда катнашучылардан тыш һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

Чишмә поселогы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

- урам яктырту җәйланмасы;

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чишмә поселогының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Лизратова